**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 елның 14 октябре №565

Махсус хәрби операциядә катнашучы хәрбиләргә һәм аларның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) өстәмә ярдәм күрсәтү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның Россия Федерациясе Бюджет кодексының 86 статьясындагы 1, 2 пунктлары, 33 статьясындагы 2 өлеше, 52 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарга, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләргә һәм затларга, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнарга, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнарга, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре, шулай ук югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) яисә махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә алган Хәрби җәрәхәт аркасында инвалид булган граңданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) (алга таба - гаиләләр) түбәндәге өстәмә ярдәм чаралары билгеләргә:

1.1. Спот ,мәдәни һ.б.чараларга бару өчен гаиләләргә (гаилә әгъзаларына) бушлай транспорт бирү .

1.2. Кама Тамагы районы Башлыгы белән шәхси очрашулар вакытында МХО хәрбиләре өчен азык-төлек җыелмалары сатып алу

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының финанс-бюджет палатасында әлеге карарның 1.1 - 1.2 пунктларында күрсәтелгән чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (социаль мәсьәләләр буенча) Е.В. Сороковнинага әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән гражданнар санына даими мониторинг үткәрергә, ярдәмнең вакытында күрсәтелүе максатларында.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы Р.Р. Баржанов